**СОВЕТ ГОРОДА МАМАДЫШ МАМАДЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
ул. М. Джалиля, 23/33, г. Мамадыш, 422190

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ МАМАДЫШ ШӘҺӘРЕ СОВЕТЫ**
М.Җәлил ур., 23/33, Мамадыш ш., 422190

тел.:(85563) 3-15-90, факс 3-24-00 ; e-mail:gorsovet.mamadysh@tatar.ru

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**
**№ 1-19** **от « 20 » сентября 2017 г.**

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Мамадыш шәһәре Советының 2014 нче елның 18 нче октябрендә кабул ителгән 1-26 нчы номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Мамадыш шәһәре территориясендә гражданнарның үзара салымын җыю һәм куллану тәртибе турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 56 статьясы, «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Мамадыш шәһәре» муниципаль берәмлеге Уставының 11 статьясы нигезендә 11 Устава муниципального образования город Мамадыш Мамадышского муниципального района Республики Татарстан», Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Мамадыш шәһәре Советы

карар кабул итте:

1. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Мамадыш шәһәре Советының 2014 нче елның 18 нче октябрендә кабул ителгән 1-26 нчы номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Мамадыш шәһәре территориясендә гражданнарның үзара салымын җыю һәм куллану тәртибе турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр һәм өстәмәләр (1 нче кушымта).

.«Үзара салым акчаларын җыю тәртибе Мамадыш муниципаль районы Мамадыш шәһәре башкарма комитетыны хокукый акты белән билгеләнә».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Мамадыш шәһәренең махсус мәгълүмат стендларында, Мамадыш муниципаль районының http://mamadysh.tatarstan.ru рәсми сайтында, Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында (pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольгә алуны Мамадыш муниципаль районы Мамадыш шәһәре башлыгы А.П.Ивановка йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Мамадыш муниципаль районы
Мамадыш шәһәре башлыгы,
шәһәр Советы рәисе А.П. Иванов

Татарстан Республикасы
Мамадыш муниципаль районы
Мамадыш шәһәре Советының
20 сентябрь, 2017 ел, № 1-19
кааррына 1 нче кушымта

1. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Мамадыш шәһәре Советының 2014 нче елның 18 нче октябрендә кабул ителгән 1-26 нчы номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Мамадыш шәһәре территориясендә гражданнарның үзара салымын җыю һәм куллану тәртибе турындагы нигезләмәгә кертелүче үзгәрешләр

**1. Нигезләмәнең 5 статьяның 5.1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:**

5.1 Гражданнарның үзара салым акчаларын түләү әлеге карарны халыкка җиткергәннән соң 3 ай эчендә, яшәү урыны җирле референдумда катнашуга һәм тавыш биргәндә чагылдырылган мөнәсәбәтләргә бәйсез рәвештә, 1 төркем инвалидлары, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннары һәм тыл хезмәтчәннәре, аларның саны Торак пунктта яшәүчеләрнең гомуми санының 30% тан артмаган очракта, Җирлек чикләрендә яшәүче 18 яшькә җиткән барлык гражданнар тарафыннан башкарыла. Түләү торак пунктның Башкарма комитетының банк реквизитларын, шулай ук түләү тәртибе турында мәгълүматны үз эченә алган торак пункт Башкарма комитетының хәбәрнәмәсе нигезендә түләнелә.